ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УЛЬЯНКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УЛЬЯНКОВО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 16 нчы сентябрь Ульянково авылы № 11

**Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Ульянково авыл җирлегендә җирле
референдум үткәрү инициативасы
турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 нче Федераль законның 56 нчы маддәсе, «Россия Федерациясе гражданнарынын төп сайлау хокуклары гарантияләре һәм референдумда катнашу хокукы турында»гы 2002 елнын 12 июнендәге 67 нче Федераль законның 15 нче маддәсе, Татарстан Республикасының «Җирле референдум турында»гы 2004 елның елның 25 мартындагы 23 нче законынның 12 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Ульянково авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турындагы инициативаны, җирле референдум мәсьәләләрен формалаштырып, түбәндәгечә тәкъдим итәргә:

"Сез 2020 елда 18 яшькә җиткән, референдумда тавыш бирергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә хокуклы Ульянково авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын бер тапкыр түләү кертүгә килешәсезме?

*а) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;

*б) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге*

*автомобиль юлларына карата эшчәнлек:*

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, мәгълүмати стендларда һәм Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://ulyan-kaybici.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Советына җибәрергә.

4. Карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Татарстан Республикасы Кайбыч**
**муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **Ф.А.Сундурова**

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ Ульянковского сельского поселения